**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 елның 23 августы № 147

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 49 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 02 сентябрендәге 96 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 49 номерлы карары белән расланган Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 02 сентябрендәге 96 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2023 елның 23 августындагы 147 номерлы карары белән расланган Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге»**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**